**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2021 №13

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агачларны, куакларны кисү, кронлаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны бетерү (Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән) хезмәтләре күрсәтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында » 2021 елның 12 августындагы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Агачларны, куакларны кисү, кронлаштыру, утырту һәм күчереп утырту, газонны бетерү (Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән) хезмәтләре күрсәтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 12 августындагы 11 номерлы карары белән расланган агач, куаклар кисүгә, кронлау, утыртуга һәм газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «агачлар, куакларның авариясе турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктны төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында. «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3.пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә аеруча кирәк булган (авария хәлендәге агачларны) яшел утыртмаларны сүтү кирәклеген расламау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкаруга яисә яшел утыртмаларны җимерүгә бәйле очраклардан тыш (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яисә яшел үсентеләрне сүтү өчен яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның егылу куркынычын бетерү өчен) » сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктны төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында «;мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә һичшиксез яшел үсентеләрне сүтү өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның егылу куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентның 2 нче кушымтасында «авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Сарман муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http:// www.sarmanovo.tatar.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р. А. Исламова